СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«НОВОЧЕРШИЛИНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Заречная ул., дом 25,
поселок Новочершилинский,
Лениногорский район, 423274

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЯҢА ЧЫРШЫЛЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Заречная урамы, 25 нче йорт,
Яңа Чыршылы поселогы,
Лениногорск районы, 423274

Тел./факс: (8-85595) 3-04-32, Nchersh.Len@tatar.ru, leninogorsk.tatarstan.ru

Р Е Ш Е Н И Е　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

№ 18　　　　　　　　　　　　　　2021 елның　«30» июне 2021 г.

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2020 елның 15 декабрендәге Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 2021 елга һәм 2022-2023 елларның план чорына бюджеты турында 14 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карар бирде:

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2020 елның 15 декабрендә кабул ителгән 14 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 2021 елга һәм 2022, 2023 елларның планлы чорына бюджеты турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

Бюджетның керем өлешенең КБК *926 202 45160 10 0000 150 буенча* 506 362,61 сумга артуы сәбәпле, аларны бюджетның чыгым өлешен арттыруга юнәлтергә:

1) 1 405,95 сумны бюджетның чыгым өлешен арттыруга 0104 «Россия Федерациясе Хөкүмәте Эшчәнлеге» бүлеге буенча канцтоварлар сатып алуга;

2) 21 786,66 сумны бюджетның чыгым өлешен арттыруга 0102 «РФ субъектының югары вазыйфаи заты эшчәнлеге» бүлеге буенча башлыкның премиясенә юнәлдерергә;

3) 483 170, сумны бюджетның чыгым өлешен арттыруга 0409 «Юл хуҗалыгы бүлеге буенча» юлларны кардан чистартуга, чокырларны ямау һәм вак таш җәюгә юнәлдерергә;

Бюджетның керем өлеше КБК 926 11714030100000150 буенча артуы сәбәпле, җирлекләр бюджетларына күчерелә торган гражданнарның үзара салымы акчалары 123 500,0,0 сумны, юлларны кардан чистарту һәм чокырларны ямау һәм вак таш җәю өчен «Юл хуҗалыгы» 0409 бүлеге буенча бюджетның чыгым өлешен арттыруга юнәлдерергә.

Бюджетның чыгым өлешенең 2021 елның 1 гыйнварына үзара салым акчасы калдыклары исәбенә 21 500,0 сумга артуы сәбәпле, аларны «Юл хуҗалыгы» 0409 бүлеге буенча юлларны кардан чистартуга һәм вак таш түшәүгә юнәлдерергә.

Бюджетның чыгым өлеше 2021 елның 1 гыйнварына җирле бюджет акчалары исәбеннән 54 123,98 сумга арту сәбәпле, аларны бюджетның чыгым өлешен арттыруга юнәлдерергә :

0503 «Торак-коммуналь хуҗалыгы бүлеге буенча» 9001,98 сумны урам яктырту буенча кредит бурычларын түләүгә;

0104 «Россия Федерациясе Хөкүмәте Эшчәнлеге» бүлеге буенча 20 122,0 сумны җирле үзидарә көненә премия түләүгә;

0310 «Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү» бүлеге буенча 20 000,0 сумны торак пунктлар һәм урман полосалары чикләрен янгынга каршы сөрүгә һәм урман суыртуына;

0801 «Мәдәният» бүлеге буенча 5 000,0 сумны 9 Май бәйрәменә бүләкләр алуга.

1. 2021 елга бюджетның төп характеристикаларын расларга:

1) «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәренең гомуми күләмен 17 274 812,61 сум итеп;

2) «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 17 350 436,59 сум итеп;

3) «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты 75 623,98 сум итеп, аны 2021 елның 01 гыйнварына җирле бюджет акчаларының калган өлешен каплауга җибәререп.

2. «Яңа Чыршылы авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын расларга:

- 2021 елга әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә.

3. «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетында 2021 елга керемнәр күләмен әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә расларга.

4. «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын расларга: әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә.

5. «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм төркемнәре буенча бүлүне расларга: 2021 елга әлеге карарның 6 нчы кушымтасы нигезендә.

6. Әлеге карарны Яңа Чыршылы п., Заречная ур., 25, Центральная ур., 12А адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга. (http://leninogorsk.ru)"Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
“Яңа Чыршылы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе

Р.Ә. Мөхәммәтшина